ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 27.11.2024 **КАРАР**
1934

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәре территориясендә салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә гарантияләүче оешманы билгеләү турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Алабуга муниципаль районы чикләрендә өзлексез су белән тәэмин итү һәм су чыгыру максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәре территориясендә салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә гарантияләүче оешманы билгеләү турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 55 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыятен Алабуга шәһәре, сәнәгать мәйданчыгы чикләрендә, шулай ук «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ территорияләрен салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендә гарантияләүче оешма сыйфатында билгеләргә.

1.2. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гарантияләүче оешманың эшчәнлек зонасы булып Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе, сәнәгать мәйданчыгы, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ территориясе торуын билгеләргә».

2. Әлеге карар муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында рәсми бастырып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025